ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ФЕДОТОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ФЕДОТОВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 феврале № 1

Федотовка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 2018 елның 19 сентябрендәге 10нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 13 ноябрендәге 83-ЗРТ номерлы «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Федотовка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 2018 елның 19 сентябрендәге 10 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1 пунктта «2.2» һәм «2.7» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Административ беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 10нчы номерлы карарындагы кушымтада «2.2» һәм «2.7» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) таблицада «Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының 2.2 статьясы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең

сайланулы органы әгъзасы/ “Федотовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре)»; - “Федотовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарының (сәркәтибе) законлы таләпләрен үтәмәү һәм "Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының 2.7 статьясы муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу/ «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы; - «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) сүзләре кергән юлларны төшереп калдырырга.

2. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазыйфаи инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны Федотовка авыл җирлегендәге Федотовка авылы, Совет урамы, 6 нчы йорт, Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм “Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

“Федотовка авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге Башлыгы В.И. Павлова